Тасмаларда - батырлык: [8нче балалар китапханәсендә «Георгий тамгасы» дигән мастер-класс үтте] // Көмеш кыңгырау. – 2025. - №10 (15 март). – Б. 2.



# Тасмаларда – батырлык





**Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан, Яр Чаллының 8нче балалар китапханәсе хезмәткәрләре 8нче урта мәктәптә «Георгий тамгасы» дигән мастер-класс үткәрде.**

Георгий тасмасы – батырлык һәм патриотлык символы. Патриотик брошь ясар алдыннан, китапханәчеләр аның тарихы һәм мәгънәсе белән дә таныштырдылар.

Мастер-класс өчен тасма, энә, җепләр, төрле декоратив элементлар кирәк булды. Китапханәчеләр ярдәмендә һәр бала үзенә уникаль Георгий тамгасы иҗат итте.

Эш мавыктыргыч барды: балалар бик теләп тасмаларның төсен сайлады һәм бизәкләр ясады. Алар идеяләр белән уртаклашты һәм бер-берсенә ярдәм итте.

Мондый кызыклы дәресләр дуслаштыра да, иҗади сәләтне дә үстерә, патриотик хисләр дә тәрбияли.



Фотолар шәхси архивлардан.